**ГЛАВА ЧЕРНЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район,, д.Чернышевка, ул. Клубная, 1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕРНЫШЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чернышевка авылы, Клуб ур.,1

Тел./факс: +7(84365) 73-5-05, e-mail: Chern.Vsg@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«30» октябрь, 2019 г.** **№ 1**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы** Чернышевка **авыл җирлегенең** Чернышевка **торак пунктларында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 21октябрендәге 196 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында», Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2019 елның 8 ноябрендә 17 сәгать 00 гә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә: Чернышевка авылы, Клуб урамы, 1 йорт.
2. 2019 елның 15 ноябрендә 17 сәгать 00 гә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә: Чернышевка авылы., Клуб урамы, 1 йор.
3. Чернышевка авылы халкы исемлеге гражданнар җыенын үткәрү өчен территориаль билгеләр буенча бүленгән:

А) Беренче этап - Центральная, Садовая, Зеленая, Лесная, Школьная, Клубная, Дорожная урамнары.

Б) Икенче этап - Листопадная, Светлая Рябиновая, Молодежная Полевая, Кленовая, Луговая, Овражная, Яхина, Г.Камала, Г.Тукая, Балкыш, Мира, М.Джалиля, Прибрежная, Ягодная, Высокогорская, Казанская, С.Сайдашева, Северная, Озёрная урамнары.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

Чернышевка торак пунктында: «2020 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлегенең Чернышевка торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Чернышевка авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру;

- Күпфатирлы йортларның йорт яны территориясен коймалар кую Чернышевка авылы;

-Чернышевка авылы җирләнгән урынга керү юлын төзекләндерү, Күмү урыннарын киртәләү;

-Чернышевка авылы эчендәге юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу;

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көненнән алып 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе
Авыл җирлеге башлыгы О.А.Маланин